Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы

Боерык

22.07.2013 ел Казан ш. №17-69

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” Федераль законның 22 һәм 48 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 30.12.2012 ел, №295-ФЗ Федераль законга, “Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында” Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 05.04.2013 ел, №57-ФЗ Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” Федераль законга туры китереп, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.06.2007 ел, №11-51 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 20.06.2011 ел, №11-60, 21.09.2011 ел, №11-83 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6. пунктта:

“в” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“в) “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә һәм 60.1 статьясындагы 9 өлешендә күздә тотылган очракларда, гражданлык хезмәткәрен гражданлык хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә”;

“г” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“г) “гражданлык хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданин) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә”;

2.4 пунктның беренче абзацында “Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

Түбәндәге эчтәлектәге 2.4.1 пунктны өстәргә:

“Конкурс комиссиясе составына, бу Нигезләмәнең 2.4 пунктында күрсәтелгән затлар белән беррәттән, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет вәкилләре кертелә. Әлеге вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.”;

2.7 пунктка түбәндәге эчтәлектәге җөмләне өстәргә:

“Министрлыкта фәкать дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче әгъзалар катнашында гына конкурс комиссиясе утырышларын үткәрү рөхсәт ителми.”;

3.3 пунктның “е” пунктчасында “086/У” сүзен “Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән медицина учреждениесе бәяләмәсе” дигән сүзләргә алыштырырга;

әлеге Нигезләмәгә №1 кушымтага түбәндәге эчтәлектәге 3 пунктны өстәргә:

“3. Дәүләти гражданлык хезмәтен үтү шартлары: _____________

_____________________________________________________________

________________.”;

3-6 пунктларны 4-7 пунктлар дип исәпләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин